| | | |
|---|---|---|
| **МИНИСТЕРСТВО СЕЛЬСКОГО ХОЗЯЙСТВА И ПРОДОВОЛЬСТВИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ ҺӘМ АЗЫК-ТӨЛЕК МИНИСТРЛЫГЫ** |

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

17.05.2024 г.Казань № 128/2-пр

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының «Дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы комиссиясе турында» 2023 елның 13 октябрендәге 384/2-пр боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 25 гыйнварындагы 71 номерлы Указы нигезендә, шулай ук кадрлар үзгәрешләренә бәйле, б о е р а м:

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының «Дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы комиссиясе турында» 2023 елның 13 октябрендәге 384/2-пр номерлы боерыгына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

күрсәтелгән боерык белән расланган Дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы комиссиясе турындагы нигезләмәдә:

1.3 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Министрлыкта Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан (алга таба – дәүләт хезмәткәрләре) «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда (алга таба – «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль закон), башка федераль законнарда билгеләнгән чикләүләрнең һәм тыюларның, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яисә җайга салу турындагы таләпләрнең, бурычларның үтәлүен (алга таба – хезмәт тәртибенә таләпләр һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турында таләпләр) тәэмин итүдә;»;

3.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле «е» пунктчасы өстәргә:

«е) дәүләт хезмәткәренә хезмәт тәртибенә таләпләрне һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турындагы таләпләрне үтәүгә тоткарлык тудыручы аңа бәйле булмаган шартлар барлыкка килү турында хәбәр итү.»;

3.4.1 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4.1. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасының бишенче абзацында һәм «е» пунктчасында күрсәтелгән хәбәрнамәләрне коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы зат карый, ул хәбәрнамәләрне карау нәтиҗәләре буенча дәлилле бәяләмәләр әзерли. »;

3.4.2 пунктында «3.1 пунктының «д» пунктчасында» сүзләрен «3.1 пунктының «д» һәм «е» пунктчаларында» сүзләренә алмаштырырга;

3.4.3 пунктында:

«а» пунктчасында «3.1 пунктының «д» пунктчасында» сүзләрен «3.1 пунктының «д» һәм «е» пунктчаларында» сүзләренә алмаштырырга;

«в» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«в) әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасының икенче һәм бишенче абзацларында, «д» һәм «е» пунктчаларында күрсәтелгән мөрәҗәгатьләрне һәм хәбәрнамәләрне алдан карау йомгаклары буенча дәлилле нәтиҗә, шулай ук әлеге Нигезләмәнең 3.13, 3.15.1, 3.15.2, 3.18 пунктлары нигезендә карарларның берсен яисә башка карар кабул итү өчен тәкъдимнәр.»;

3.7 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.7. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «д» һәм «е» пунктчаларында күрсәтелгән хәбәрнамәләр, кагыйдә буларак, Комиссиянең чираттагы (план) утырышында карала.»;

3.8 пунктта «3.1 пунктындагы «б» пунктчасы» сүзләрен «3.1 пунктындагы «б» һәм «е» пунктчалары» сүзләренә алмаштырырга;

3.8.1 пунктының «а» пунктчасында «3.1 пунктындагы «б» пунктчасы» сүзләрен «3.1 пунктындагы «б» һәм «е» пунктчалары» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле 3.15.2 пункт өстәргә:

«3.15.2. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «е» пунктчасында күрсәтелгән мәсьәләне карау йомгаклары буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) дәүләт хезмәткәренә бәйле булмаган шартларның барлыкка килүе һәм хезмәт тәртибенә таләпләрне һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турындагы таләпләрне үтәү мөмкин булмавы арасында сәбәп-нәтиҗә бәйләнеше булуын танырга;

б) дәүләт хезмәткәренә бәйле булмаган шартларның барлыкка килүе һәм хезмәт тәртибенә таләпләрне һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турындагы таләпләрне үтәү мөмкин булмавы арасында сәбәп-нәтиҗә бәйләнеше булмавын танырга.»;

3.19 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.19. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «а», «б», «г», «д» һәм «е» пунктчаларында күрсәтелгән мәсьәләләрне карау нәтиҗәләре буенча Комиссия, нигезләр булганда, әлеге Нигезләмәнең 3.11 - 3.15.2, 3.17, 3.18 пунктларында

каралганнан тыш, башка карар кабул итәргә мөмкин. Мондый карар кабул итүнең нигезләре һәм мотивлары Комиссия утырышы беркетмәсендә чагылдырылырга тиеш.»;

Дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы комиссиясенең әлеге боерык белән расланган составында:

түбәндәгеләрне чыгарырга:

Ибраһимов Ренат Рәшит улын һәм Шувалова Диләрә Даниял кызын;

түбәндәгеләрне кертергә:

Галимҗанов Алмаз Илдус улын – Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының аудит һәм коррупциягә каршы эш бүлеге башлыгы;

Заһидуллина Миләүшә Мөдәрис кызын – «Татарстан Республикасының аграр яшьләр берләшмәсе» төбәк иҗтимагый оешмасы рәисе (килештерү буенча).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры урынбасары – министр М.А. Җәббаров